# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Синерь поселогында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

15 ноябрь, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Синерь поселогында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Синерь поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 4200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

2) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (яр буе зоналарын чистарту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

5) торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

6) традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Синерь авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре).

3. Әлеге карарны Починок Кучук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Починок-Кучук авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Г.И. Петров